**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Кората авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

**2014 елның 28 мае** **14№**

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Кората авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм алардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында**

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Кората авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 79 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Кората авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Кората авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм алардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Кората авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Иске Кората авыл җирлеге башлыгы С.В.Новиков

Татарстан Республикасы Әлки
муниципаль районының Иске
Кората авыл җирлеге Советының
2014 елның 28 маендагы 14
номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Кората авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм алардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Кората авыл җирлеге (алга таба - Җирлек) территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм алардан файдалану тәртибен җайга сала.

2.1. Гражданнар - яшәү урыны Җирлек чикләрендә урнашкан Россия Федерациясе гражданнары.

Гражданнарның үзара салым акчалары дигәндә гражданнарның җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен башкарыла торган түләүләре аңлашыла.

Гамәлдәге законнар, җирлек уставы нигезендә, җирлек чикләрендә яшәү урыны буенча теркәлгән Россия Федерациясе гражданнары арасында үзара салым мәсьәләсе буенча яшерен тавыш бирүдә гражданнарның гомуми тигез һәм турыдан-туры ихтыярын белдерү нигезендә үткәрелә торган референдум.

2. Гражданнарның үзара салым мәсьәләсе буенча референдум үткәрү турында инициатива күрсәтү

2.1. Үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда хәл ителә.

2.2. Гражданнарның үзара салымы мәсьәләсе буенча җирле референдум уздыру инициативасына керә:

- җирле референдумда катнашу хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары;

- уставында сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда катнашу каралган һәм федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда теркәлгән сайлау берләшмәсе, башка иҗтимагый берләшмә;

- Бергә тәкъдим иткәндә авыл җирлеге советы һәм авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе.

3. Җирле референдумны билгеләү, әзерләү һәм уздыру

3.1. Җирле референдумны билгеләү турындагы карар Җирлек советы тарафыннан Советка җирле референдум билгеләнә торган документлар кабул ителгән көннән алып 30 көн эчендә кабул ителә.

3.2. Җирле референдумны әзерләү һәм уздыру тәртибе 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында» 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән җайга салына.

3.3. Җирле референдумны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанслау Җирлек бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

## 4. Җирле референдум карары

4.1. Гражданнарның үзара салымы җирлек территориясендә җирле референдумда кабул ителгән карар буенча кертелә.

4.2. Референдум үзара салым буенча түләү күләмнәрен һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итүне раслый. Гражданнарның үзара салым тәртибендә түләүләр күләме, гражданнарның аерым категорияләреннән тыш, җирлектәге барлык граждланнар өчен дә абсолют зурлыкта тигез дип билгеләнә.

4.3. Тавыш бирү йомгаклары һәм җирле референдумда кабул ителгән карар мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән һичшиксез халыкка җиткерелергә тиеш.

Җирле референдумда кабул ителгән карар рәсми игълан ителгән вакыттан үз көченә керә.

4.4. Үзара салым кертү турында референдум карары Җирлекнең барлык гражданнары өчен дә мәҗбүри булып тора.

## 5. Үзара салым акчаларын җыю тәртибе

5.1. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү әлеге карар игълан ителгәннән соң 12 ай эчендә, 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә урнашкан 18 яшькә җиткән барлык гражданнар тарафыннан, аларның җирле референдумда катнашуына һәм тавыш биргәндә чагылдырылган мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, төп халыкның 30% артмаган хәлдә,1 һәм 2 группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алуның көндезге формасында белем алучы студентлардан, күпбалалы гаиләләрдән тыш, "Әлки районының Бердәм исәп-хисап үзәге" ҖЧҖнең банк реквизитларын, шулай ук түләү тәртибе турында мәгълүматны үз эченә алган хәбәрнамәсе нигезендә түләнә.

5.2. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар "Әлки районының бердәм исәп-хисап үзәге" ҖЧҖенең шәхси счетына керә.

Үзара салым тәртибендә җыелган акчалар җирлек бюджетына күчерелә.

5.3. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар (алга таба - исәп-хисап оешмалары) аша почта күчермәләрен гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла.

5.4. Түләү фактын касса ордерының квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлары раслый.

## 6. Үзара салым акчаларыннан файдалану

6.1. Үзара салым тәртибендә җыелган һәм әлеге Нигезләмәнең 5.1 пункты нигезендә җирлек бюджетына кергән акчалар җирле референдумда кабул ителгән карарда каралган җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне (конкрет мәсьәлә) хәл итүгә җирлек башкарма комитеты тарафыннан тотыла.

6.2. Җирлек бюджетына кергән хисап елында файдаланылмаган акчалар киләсе финанс елына күчә һәм референдум карары белән каралган максатларга тотыла.

6.3. Җирлек башлыгы елга бер тапкыр җирле референдумда кабул ителгән карарның үтәлеше турында Җирлектә яшәүчеләргә хисап тота.

6.4. Әлеге Нигезләмәнең 6.3 пункты нигезендә әзерләнгән Җирлек башлыгының хисаплары җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелә.

6. 5. Үзара салым акчасына түләүнең тулылыгын һәм үз вакытында башкарылуын тикшереп торуны Җирлекнең башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

## 7. Әлеге Нигезләмәне бозган өчен җаваплылык

7.1. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

7.2. Акчаларны максатчан файдалануны тикшереп тору Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Контроль-хисап палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.